**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 ноябрендәге 3858 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1439 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатыннан карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1439 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 4716 номерлы, 2018 елның 26 сентябрендәге 5087 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге 434 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 1104 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 1492 номерлы, 2019 елның 9 сентябрендәге 3162 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 919 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге 2969 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 2763 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 3073 номерлы, 2022 елның 8 февралендәге 405 номерлы, 2022 елның 23 июнендәге 1978 номерлы, 2022 елның 8 августындагы 2610 номерлы, 2022 елның 3 ноябрендәге 3821 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы 19 номерлы, 2023 елның 8 августындагы 2235 номерлы, 2023 елның 13 октябрендәге 3071 номерлы, 2024 елның 21 февралендәге 600 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 1292 номерлы, 2024 елның 12 апрелендәге 1527 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2003 номерлы,

2024 елның 1 июлендәге 2768 номерлы, 2024 елның 24 июлендәге 3087 номерлы, 2024 елның 1 августындагы 3209 номерлы, 2024 елның 4 сентябрендәге 3769 номерлы, 2024 елның 20 декабрендәге 5326 номерлы, 2025 елның 16 гыйнварындагы 39 номерлы, 2025 елның 10 февралендәге 329 номерлы, 2025 елның 6 мартындагы 562 номерлы, 2025 елның 23 маендагы 1617 номерлы, 2025 елның 1 июлендәге 2013 номерлы, 2025 елның 21 июлендәге 2315 номерлы, 2025 елның 17 сентябрендәге 2905 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 6 номерлы кушымтада 9 пунктны әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

2. Кертелә торган үзгәрешләр 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 ноябрендәге
3858 номерлы карарына
кушымта

**2025 елга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге карамагындагы аерым муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр хезмәткәрләренең база окладларына һәм хезмәт хакы ставкаларына арттыру коэффициентлары**

| № т/б | Хезмәткәрләре окладларына (хезмәт хакы ставкасына) арттыру коэффициенты билгеләнә торган учреждениеләр | Вазифа атамасы | Окладка (хезмәт хакы ставкасына) арттыру коэффициенты |
|---|---|---|---|
| 9 | «Шәһәр парковка киңлеген оештыручы» муниципаль казна учреждениесе | Әйдәүче инженер-программист | 0,87 |

___________________